МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.11.2019 г.Казань № 1014

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 11 декабрендә 5986 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 8 июнендәге 406 номерлы боерыгы белән расланган Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү шартнамәсе буенча түләнгән иминиятләштерү премиясенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү шартнамәсе буенча түләнгән иминиятләштерү премиясенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык

җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү шартнамәсе буенча түләнгән иминиятләштерү премиясенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 8 июнендәге 406 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2014 №312, 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №402, 16.01.2017 №10, 08.06.2017 №348, 12.02.2018 №110, 15.05.2018 №365, 19.09.2018 №887, 03.09.2019 №667 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү шартнамәсе буенча түләнгән иминиятләштерү премиясенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 14.11.2019 № 1014 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү шартнамәсе буенча түләнгән иминиятләштерү премиясенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 8 июнендәге 406 номерлы боерыгы белән расланган Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү шартнамәсе буенча түләнгән иминиятләштерү премиясенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба текст буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында күрсәтелгән. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.3 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 1.4.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «яки шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү шартнамәсе буенча түләнгән иминиятләштерү премиясенә компенсация (алга таба – компенсация) билгеләү | 40-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясы; Кагыйдәләрнең 4 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Инвалидның (инвалид баланың) яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлекчәсе | Кагыйдәләрнең 4 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | 40-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясының 1 пункты; Кагыйдәләрнең 7 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында | Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша үтенечләр җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап алты эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты | Кагыйдәләрнең 7 п. |

| | | |
|---|---|---|
| туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң ун эш көненә кадәр озайтыла.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Гариза. Әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына туры китерелгән формада гариза.<br>2. Милекчесе сыйфатында инвалид (инвалид бала) яки инвалид баланың законлы вәкиле күрсәтелгән транспорт чарасы паспортының күчермәсе;<br>3. Транспорт чарасы хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү полисы күчермәсе;<br>4. Килешү буенча иминият премиясен түләү турында квитанция күчермәсе;<br>5. Инвалидта (инвалид балада) медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан билгеләнгән транспорт чаралары белән тәэмин итүгә медицина күрсәткечләре булуын раслаучы документ.<br>Үзәк бүлегендә инвалидның (инвалид баланың) медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан билгеләнгән транспорт чаралары белән тәэмин итүгә медицина күрсәткечләре булуын раслаучы документ булган очракта, гариза бирүче күрсәтелгән документны тапшыру зарурлыгыннан азат ителә.<br>Гариза бирүчеләр мөрәҗәгать иткәндә шәхесне таныклый торган документны күрсәтә һәм банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын тапшыра.<br>Инвалидның (инвалид баланың) законлы вәкилләре өстәмә | Кагыйдәләрнең 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | рәвештә аларның статусын һәм вәкаләтләрен таныклаучы документ күчермәсен тапшыра.<br>Гариза бирүчеләр тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар өстәмә рәвештә гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыра.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча хезмәттән | |

| | | |
|---|---|---|
| актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | файдаланучының хосусый шәхси счеты иминият номеры турында белешмәләрне раслый торган документлар алына (Россия Федерациясе Пенсия фондында).<br>Гариза бирүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Гариза бирүченең яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе | Кагыйдәләрнең 4 пункты, 7 пункты |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Ялган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торучы документларны тапшыру дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора | 40-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясының 1 пункты; Кагыйдәләрнең 3 п. |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | билгеләнмәгән | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар кергән көннән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | 880 номерлы тәртипнең 2.4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин | 880 номерлы тәртипнең 2.4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау | итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре:<br>документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша, шул исәптән электрон почта аша, җибәргәндә – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә гариза бирүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган кирәкле барлык документлар тапшырылган очракта, хезмәттәшлек итү зарурлыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлык сайтында http://mtsz.tatarstan.ru, Дәүләт һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында (http://uslugi.tatar.ru/), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://www.gosuslugi.ru/) алынырга мөмкин;<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Үзәк бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән һәм (яки) мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә, шулай ук гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә электрон саклагычлардан файдаланып та тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш | Нигезләмәнең 10, 11 пунктлары; 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 11 пункты; 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$, $21^2$ статьялары»; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктта:

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;»;

6 һәм 7 пунктчаларны гамәлдән чыккан дип танырга;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.3 пунктта:

3.3.3.1 һәм 3.3.3.2 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәкнең бүлек белгече гариза бирүченең хосусый шәхси счетының иминият номеры турында электрон формада мәгълүмат ала (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Россия Федерациясе Пенсия фондына гариза бирүченең хосусый шәхси иминият номеры турында белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм теркәлгән документлар килгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган белешмәләр, мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.4.1 пунктта «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.6 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.7 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3.7. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган белгечләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тарту очрагында;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган вазыйфаи заты (учреждение белгече) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның(учреждениенең) дәүләт хезмәткәренең (учреждение белгечәнең), җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затлар тарафыннан шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган вазыйфаи затының (учреждение хезмәткәренең) гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органда вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган вазыйфаи затының (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган вазыйфаи затының (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча гариза бирүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә."

5.6.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.6.2. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, Үзәк белгече булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

кушымтаны (белешмәлекне) түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

«Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү шартнамәсе буенча түләнгән иминиятләштерү премиясенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү шартнамәсе буенча түләнгән иминиятләштерү премиясенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |